ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентябрь, 2017 ел № 19/5

Муниципаль учреждение
хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне
арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 27 июлендәге «Хезмәтләренә түләү Татарстан Республикасы бюджет сферасы хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүнең бердәм тариф челтәреннән тыш исәпләнүче бюджет оешмасы хезмәткәрләренең 2017 елның 1 октябреннән вазифаи окладларын арттыру турында» 523 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 2 августындагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 538 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы «Татарстан Республикасы бюджетара мөнәсәбәтләрен формалаштырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын исәплгәндә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларында бюджет чыгымнарын билгеләү турында» 569 санлы Карарына нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Хезмәтләренә түләү бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнмәгән бюджет учреждениеләре җитәкчеләре, житәкчеләрнең беренче урынбасарлары, урынбасарлар, хезмәткәрләр, белгечләрнең хезмәтләренә түләүне 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә).

Әлеге пунктта күрсәтелгән хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне һәм

вазифаи окладларын, шулай ук хезмәт хакын арттыру (индексацияләү) максатында айлык һәм башка төр өстәмәләрне хисаплагандә сумманы арту ягына исәпләп, бер сумга кадәр түгәрәкләргә.

2. Хезмәткә түләү шартлары регулярлаштырылучы муниципаль учреждение хезмәткәрләренә 2017 елның 1 июленнән 1 580,00 сум күләмендә өстәмә түләү билгеләргә:

1) Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләү шартларын билгеләү турында» 39/8 нчы санлы Карары (2016 елның 8 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9, 2017 елның 29 мартындагы 16/6 санлы Карарлары редакциясендә);

2) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Шәһәр Советының 2010 елның 26 августындагы 53/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең аерым муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәткә түләүнең яңа системасы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 22/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 23/6, 2013 елның 30 маендагы 25/7, 2013 елның 29 августындагы 26/5, 2014 елның 10 июлендәге 31/7, 2014 елның 9 декабрендәге 35/7, 2015 елның 15 апрелендәге 39/8, 2017 елның 29 мартындагы 16/6 санлы Карарлары редакциясендә) нигезләнеп.

Карарның әлеге пункты белән каралган өстәмә түләү ай саен эш периодының вакытына тәңгәл рәвештә түләнә.

3. Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/5 санлы Карары белән расланган хезмәтләренә түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә гамәлгә ашырылучы Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«7. Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисапланучы хезмәткәрләргә компенсация түләүләре күләме

| Бердәм тариф челтәре буенча хезмәт хакы түләү разрядлары | Компенсация түләүләре куләме, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 3 383,0 |
| 2 | 3 283,0 |
| 3 | 3 193,0 |
| 4 | 3 082,0 |
| 5 | 2 805,0 |

| | |
|---|---|
| 6 | 2 780,0 |
| 7 | 2 704,0 |
| 8 | 2 692,0 |
| 9 | 2 692,0 |
| 10 | 2 680,0 |
| 11 | 2 673,0 |
| 12 | 2 673,0 |
| 13 | 2 673,0 |
| 14 | 2 673,0 |
| 15 | 2 673,0 |
| 16 | 2 673,0 |
| 17 | 2 673,0 |
| 18 | 2 673,0»; |

2) Түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пунктын өстәргә:

«11.1. Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазифаи оклады 7 210 сумны тәшкил итә. Оператив дежур хезмәткәрләрнең вазифаи окладоы 6 560 сумны тәшкил итә.»;

1) 13 пунктны түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«13. Оператив дежур хезмәткәрләрнең стимуллаштыру өстәмә түләүләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү – вазифаи окладның 2,4 күләмендә

| Хезмәт стажы | Өстәмә түләү куләме,% |
|---|---|
| 1 елдан 3 елга кадәр | 5 |
| 3 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 20 |
| 15 елдан артык | 30 |

2) хезмәт вазифаларын намуслы башкарган өчен календарь елы нәтиҗәләре буенча түләнүче өстәмә түләү – елына ике вазифаи оклад күләмендә.

Оператив дежур хезмәткәрләрнең компенсация түләүләренә түбәндәгеләр керә

1) Гадәти шартлардан тыш, төнлә (22:00 сәгатьтән 6:00 сәгатькә кадәр) эшләгән өчен түләү – производство календаре нигезендә ел планы буенча, төнлә эшләгән һәр сәгать һәм төнлә эшләгән гомуми вакыт өчен

вазифаи окладның 35 проценты күләмендә башкарыла;

2) эшләми торган бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен өстәмә түләү - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы белән тәгаенләнгән һәм еллык производство календаре нигезенде эшләи торган ял көннәре саны буенча;

3) дәүләт сере булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен өстәмә түләү – вазифаи окладка 1,2 күләмендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге «Даими рәвештә дәүләт сере белән эшләүче һәм дәүләт серен саклаучы структуралар бүлекчәләрендә эшләүче гражданнарга социаль гарантияләр бирү турында» 573 санлы карары белән нигезләнгән күләмдә исәпләнелә;

4) югары дәрәҗәдә оператив-техник әзерлекне тәэмин итү өчен, махсус хезмәт режимы, хезмәтнең катлаулылылга һәм киеренкелеге өчен өстәмә түләү – ел дәвамында 6 вазифаи оклад күләмендә. Әлеге өстәмә түләү күләме вазифаи окладның 50 процентыннан артмаска тиеш;

5) Татарстан Республикасының аерым климат шартлары булган урыннарында эшләгән өчен өстәмә түләү - вазифаи оклад, өстәмә түләү һәм әлеге пунктта күрсәтелгән еллык өстәмә түләү суммасына 1,15 күләмендә.»;

4) 27 нче, 28 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«27. Аерым оешма хезмәткәрләренең (җитәкчеләренең, җитәкченең беренче урынбасарларының, җитәкче урынбасарларының) вазифаи окладлары

| Вазифа исеме | Вазифаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Җитәкче | 7 743 |
| Җитәкченең беренче урынбасары, җитәкче урынбасарлары | 7 157 |

28. Аерым оешма хезмәткәрләренең (белгечләренең) вазифаи окладлары

| Вазифа исеме | Вазифаи оклад күләме, сумнарда. |
|---|---|
| Бүлек башлыгы, баш хисапчы | 6 070 |
| Бүлек башлыгы урынбасары, бүлекчәр мөдире | 5 463 |
| Баш белгеч | 4 944 |
| Әйдәп баручы белгеч | 4 617 |
| I категория белгеч | 4 140 |
| II категория белгеч | 3 499 |

| | |
|---|---|
| Белгечт | 2 555 |
| Архив мөдире | 2 555 |
| Өлкән инспектор, статистик, машинкада язу, күчермәләр ясау бюросы мөдире | 2 555 |
| Инспектор, статистик; хуҗалык, склад мөдире; кассир, комендант, эш кәгазьләрен алып баручы, архивариус | 2 350 |
| I категория стенографист | 2 465 |
| II категория стенографист, секретарь-стенографист, I категория машинистка | 2 350 |
| II категория машинистка, секретарь-машинистка, җитәкче секретаре, экспедитор | 2350 |

Бер үк вакытта структур бүлекчә мөдире вазифасын башкарган җитәкче урынбасарының вазифаи оклады җитәкче урынбасарының вазифаи окладында күләмендә билгеләнә.».

4. Әлеге Карарны гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны финанслау шәһәр бюджеты хисабыннан башкарыла

5. Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге «Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 9/8 санлы Карарының 1,2 пунктларын гамәлдән чыккан дип танырга.».

6. Билгеләргә

1) әлеге Карарның 1 пункты, 3 пунктның 4 пунктчасы 2017 елның 1 октябреннән гамәлгә керә;

2) әлеге Карарның 2 пункты, 3 пунктның 1 пунктчасы, 5 пункты 2017 елның 1 июленнән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала;

3) әлеге Карарның 3 пункты 2.3. пунктчалары 2017 елның 1 сентябреннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

7. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев